СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.13, д. Нижняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **N 5**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 27 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыенының Корайван авылы М. Гафури урамы, 29 йорт адресы буенча 2024 елның 07 апрелендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 27 ноябрендәге 6 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Корайван авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 800 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 400 сум

күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- һәйкәлләр кую, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга обелиск урнаштыру, территорияне төзекләндерү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Корайван авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 27 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Корайван авылы, М. Гафури урамы, 9 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина